КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 сентябрь г.Казань № 1199

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 октябрь, 731 нче; 2014 ел, 29 ноябрь, 930 нчы; 2014 ел, 12 декабрь, 982 нче; 2015 ел, 4 август, 566 нчы; 2015 ел, 5 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 27 сентябрь, 689 нчы; 2017 ел, 24 апрель, 241 нче; 2017 ел, 28 июнь, 450 нче; 2018 ел, 26 июнь, 520 нче; 2018 ел, 19 декабрь, 1173 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 754 нче; 2020 ел, 28 гыйнвар, 47 нче; 2020 ел, 16 июль, 601 нче; 2021 ел, 29 апрель, 297 нче; 2021 ел, 13 сентябрь, 863 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1327 нче; 2022 ел, 29 август, 925 нче; 2022 ел, 29 декабрь, 1454 нче; 2023 ел, 18 апрель, 484 нче; 2023 ел, 2 июнь, 675 нче; 2023 ел, 14 июль, 836 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – дәүләт программасы) расларга.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгын дәүләт программасының җаваплы башкаручысы итеп билгеләргә.»;

3 пунктта «чираттагы финанс елына» сүзләреннән соң «һәм план чорына» сүзләрен өстәргә, «Программа» сүзен «дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Программа» сүзен «дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» дәүләт программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карарның кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының актлары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин